ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 581-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 581-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2582-VI ДС

581-6 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтаның 2 пунктының 1 пунктчасына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (часть I) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) дүртенче абзацта «резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле социаль-икътисадый үсеше алга киткән территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда» сүзләрен «инвестиция проекты Россия Федерациясе монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә төзелә торган үсеше алга киткән территорияләр резидентлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән инвестиция проекты таләпләренә (алга таба – Таләпләр)» сүзләренә алмаштырырга;

2) бишенче абзацта «резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда» сүзләрен «инвестиция проекты Таләпләргә туры килгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

3) алтынчы абзацта «резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен

гамәлгә ашырганда» сүзләрен «инвестиция проекты Таләпләргә туры килгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

4) җиденче абзацта «резиденты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең тиешле территория төзү турындагы карарында билгеләнгән икътисадый эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырганда» сүзләрен «инвестиция проекты Таләпләргә туры килгәндә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә эшләнде.

Татарстан Республикасы Җир кодексында аларны урнаштыру һәм гамәлгә ашыру өчен дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрен арендага торглар үткәрмичә бирү рөхсәт ителә торган социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, масштаблы инвестицион проектлар шуларга туры килергә тиеш булган критерийлар (алга таба – Критерийлар) билгеләнгән. Шул исәптән Критерийлар үсеше алга киткән социаль-икътисади территорияләрдә гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына карата билгеләнгән.

Үсеше алга киткән социаль-икътисади территорияләр Татарстан Республикасының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 29 июлендәге 1398 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) исемлегенә кертелгән җиде шәһәренең бишесендә булдырылган.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә үсеше алга киткән территорияләрне булдыру үзенчәлекләре турында» 2015 елның 22 июнендәге 614 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә үсеше алга киткән территорияләрне булдыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертелде, үсеше алга киткән территорияләрне булдыру турындагы карарның резидентлар инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруның аерым хокукый режимы гамәлдә булмаган икътисади эшчәнлек төрләре исемлеген күздә тотуы турындагы нормалар үз көчен югалткан дип танылды.

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә Критерийларны, резидентның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең үсеше алга киткән социаль-икътисади территориясен булдыру турындагы карары белән билгеләнгән икътисади эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру шартын инвестиция проектының Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә төзелә торган үсеше алга киткән территорияләре резидентлары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектлары таләпләренә туры килүе турындагы нигезләмә белән алыштырып, төзәтергә кирәк.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.